СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

08.11.2024 Баулы шәһәре № 277

2025 елга Баулы муниципаль районының
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
Фаразлау планы (программасы) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планын (программасын) 1-нче номерлы кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Баулы муниципаль район
Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль район Советының
2024 елның 8 ноябрендәге 277 номерлы
карарына 1-нче номерлы Кушымта

## 2025 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы

### 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә эшләнгән.

1.2. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру, Баулы муниципаль районы милек структурасын оптимизацияләү, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итү, район бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән.

1.3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. Баулы муниципаль районы муниципаль милекендәге күчемсез мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. 2024 елга Баулы муниципаль районының муниципаль милеген хосусыйлаштыруның Фаразлау планына (программасына) кертелгән, хосусыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.3. Муниципаль милектә булган, муниципаль казна предприятиеләрен һәм акцияләрен 2025 елда хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. 2025 елда хосусыйлаштырырга планлаштырылган муниципаль мөлкәт исемлеге, Фаразлау планы гамәлдә булганда, яңа күчемсез милек объектлары белән тулыланырга мөмкин.

2.5. 2025 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт (1-нче номерлы таблица).

1-нче номерлы таблица

| № п/п | Объект атамасы | Урнашкан урыны (Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы) |
|---|---|---|
| 1 | 16:55:010308:56 кадастр номерлы, гомуми мәйданы 466,6 кв.м. булган торак булмаган корылма-запас частьләр склады. | Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |
| 2 | 16:55:010308:69 кадастр номерлы, гомуми мәйданы 24 970,0 кв.м. булган җир кишәрлеге. | Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |